# КҮК КАПУСЫ

Күк капусы ачылды. Һатифтан: «Шул шаулаша торган татарларны кертеңез, шуларның йомышларын сораңыз!» — дигән әмер ишетелде. Күз ачып күз йомганча фәрештәләр үзләренең халкының тормышыннан риза булмаенча, шул тормышны үзгәртергә теләүчеләрне җиде кат күк аша очыртып китереп бастырдылар.

Һатифтан тагын: «Тәйе зәмин кылыңыз, бөтен татар галәмен бергә җыеңыз, йөдәтүчеләрне дәрәҗәсе-дәрәҗәсе берлә кертеңез!» — дигән икенче әмер булды, фәрештәләр җыелган кешеләргә карап, барыдамы икәнен белеп бетергәннең соңында: «Рәхим итегез!» — дип, ишекне ачтылар. Алгы бүлмәгә җыелган «Вакыт»чы, «Йолдыз»чы, «Таң»чы, «Исляхчы», «Дөнья вә мәгыйшәт»че — барысы да берьюлы аякка калкып, залга таба бара башладылар. Бик һавалы кыяфәт берлә «Таң»чы алдан китте. Зәңгәр генә тавыш берлә «Вакыт»чы: «Әй, малай, син кая барасың, олугларга юл бир!» «Мәгыйшәт»чегә карап: «Әйдәңез, хәзрәт, әйдә, хәзрәт», — диде. «Йолдыз»чы, өстендәге кигән киемен, ятып тора микән дип, күздән кичереп: «Әйе, әйе, хәзрәт кеше!» — диде дә, авыз эченнән генә: «Шул малайлар йөдәттеләр инде», — дип куйды. «Мәгыйшәт»че истибрасын корыта-корыта, тамакларын «эһем-эһем» иттереп, аякларын тибә-тибә ишеккә таба кызулана башлады. Аның юлы алдына акыртын гына селкенә торган яшь кенә «Истилях»чыга тугры килеп, «Мәгыйшәт»че: «Юл бир, юл бир!» — дип кычкыра башлады. «Ислях»чы, аның карт ата кәҗәдән килә торган төсле исеннән җирәнеп, читкә кагылды, «Таң»чы да кайдан шул кабахәт ис килгәнне белер өчен борынын кысып артына борылды да, күз алдына кечкенә генә, сасы гына, былчырак кына куй мае, тир исе, истибра, истинҗа, тагы әллә нәрсәләр исе килә торган «Мәгыйшәт»чен күреп, чыраен сытты. «Мәгыйшәт»че боларның чырай сыткannарын күреп, көлеп «Әйе, әйе, шулаймыни, менә иманыңыз юклыгы күрендеме мөселманны күрүеңез берлә күңелеңез бозылды. Китапта әйткән...» — дип, озын гына гарәпчә бер гыйбарә укыды.

«Вакыт»чының да борынына тегенең сасысы бераз борылса да, малайларга ияpү булыр дип куркып, ул «Мәгыйшәт»ченең, исен тоймаган кебек булып аның янына ук килде. «Йолдыз»чы «Таң»чының колагына гына «Үзенә әйтә күрмә, мин кеше берлә бозылышуны яратмыйм, минем мәсләгем ул түгел, сасы бит», — диде һәм дә шуңарга җавап биргәнне дә көтмәенчә, өстенә карап «Минем казаки яхшы тегелгәнме? Яхшы ятып торамы?» — диде. «Ислях»чының моның бу сүзләреннән көлеп торганын күреп: «Юк, пакьлек яхшы, пакьлек фәнчә дә яхшы», — дип алга таба атлады.

Һәммәсе дә берьюлы ишеккә барып терәлделәр «Вакыт»чы тагы: «Хәзрәткә юл биреңез! Юл, юл, дип әйтәм әй, малайлар!» — дип кычкыра башлады. Аның сүзенә берәү дә илтифат итмәенчә, кысыла-кысыла рәтсез-чиратсыз кереп киттеләр. «Вакыт»чы матур хәтфә паласлар берлә төзелгән бүлмәдә йомшак креслолар күргәч тә, алгарак чыгып: «Яңез, хәзрәт, яңез!» — дип «Мәгыйшәт»чегә урын күрсәтте. «Мәгыйшәт»че тагы бер мәртәбә тамагын кырып, истибра кесәсеннән кулын алмаенча гына креслога утырды. Аның янына «Вакыт»чы утырып: «Менә монда, монда», — дип, «Йолдыз»чыны чакыра башлады. Зал тагы теге «Мәгыйшәт»ченең сасысы берлә тулды. «Таң»чы борынын кысып тотып, «Ислях»чы борынын җыерып, каршы яктагы өч креслоның ике кырыендагысына утырдылар. Бүлмә тынланды.

Менә тагы бик зур канатлы кошлар очкан кебек һава ярып килә торган бер тавыш ишетелде. Болар бер-берсенә караша башладылар. «Мәгыйшәт»че: «Билләһидер, бидгатьләр күбәйде», — дип, тагы бер мәртәбә «эһем-эһем» дип, истибрасын корытып: «Исмасам, тәһарәт булмаса, тәйәммем берлә хәзер булыйк»,— дип тәйәммем сугарга тотынды. «Вакыт»чы да җиңнәрен сызганырга тотынган иде, «Йолдыз»чы: «Минем тәһарәтем бар» — дигәч, теге дә: «Минеке дә бар, минеке дә» — дип яңадан утырды. «Таң»чы, «Мәгыйшәт»ченең паласларга кагынып маташуын күреп, ачуланган тавыш берлә — «Сасың җитмәгәнмени, инде тагын тузан да чыгарасың!» — диде.

«Ислях»чы: «Моны әллә иске мәдрәсәң дип белдеңме, бу «Сөлләм» дәресе түгел», — диде.

«Мәгыйшәт»че бер дә илтифат итмәенчә, һаман тәйәммем кылуында дәвам итте. «Йолдыз»чы ярты күзе берлә генә көлеп, йөзе берлә генә «Мәгыйшәт»чегә ишарә кылып, «Таң»чыга карады. Ул ара да булмады, күктән бернәрсә очып төшә башлады. «Мәгыйшәт»че тәйәммемне онытып, яңадан истибра кесәсенә кулын тыгып, куркуыннан әллә нинди әбисеннән өйрәнгән догалыкларын укый башлады.

Менә бер кара нәрсә килеп бүлмәнең уртасына басты. Басуы берлә уң якка борылып: «Бөрадәрләр, саглармысез?» — дип, тегеләрнең берсе-берсе берлә сөйләшә башлады. «Мәгыйшәт»че, тегене күргәч үк: «Ә, син «Тәрҗеман»мени? Мине куркытып истибрамны бүлдердең. Менә инде нәҗасәт, гализа хакында китап карарга кирәк була инде»,—диде. «Тәрҗеман»чы шул сүзләрне ишеткәндә, борынына искән сасы истән җирәнеп, сулга борылды. Анда «Таң»чы берлә «Ислях»чыны күргәч: «Бөрадәрләр, сез дә бурадасыз»,— дип, алар берлә сөйли башлады.

Бер минутта күктә әллә нинди бер төстә дә түгел кресло иңеп, «Тәрҗеман»чының баскан җиренә туктады, «Вакыт»чы: «Утырыңыз, утырыңыз, сез безнең беренче мөхәрриремез»,— диде. «Тәрҗеман»чы утырды. Бүлмә тынланды. Әллә нинди бик каты күк күкрәгән кебек булды, бөтен күз алды караңгыланды. Бүлмәдәге бөтен нәрсәләр хәрәкәткә килгән кебек булды. Тагы бер яшен кебек нәрсә үтте. Бүлмә ялт итеп китте. Шундагы һәммә кеше бүлмәнең үзгәргәнен күреп, бер-берсенең урыннарын, киемнәрен карый башладылар. «Мәгыйшәт»ченең утырган урыны тазлар, комганнар куелган, кызыл, яшел салфетлар эленгән, диварларына мисвәкләр сөялгән, истинҗага утырыр өчен урыннар хәзерләнгән бер тәһарәтханәгә әверелгән иде. Аның күршесендәге «Вакыт»чының креслосы матур гына, ярты аурупача, ярты татарча, диварларына әллә нинди сүзләр язылып эленгән, иң күзгә күренә торган җиренә бик зур счут куелган өстәл өстенә әллә ничә кантур кенәгәләре тулган, вак-төяк савытларга бакыр акчалар тутырылган өйгә әверелгән иде.

«Йолдыз»чының креслосы бик күп мәктәп китаплары, кәгазь чүп-чарлары берлә тулган бер бүлмә кебек булса да, аның бүлмәсе, диңгездә дулкын вакытындагы селкенә торган көймә кебек, бер менеп, бер төшеп тора кебек күренә иде. Боларның барысының да бүлмәләре өстеннән әллә нинди сәраб очып торганга, боларның «Мәгыйшәт»чесенең төсе, һавасы һәм киеме һаман каралыгын югалтмаса да, «Вакыт»чы берлә «Йолдыз»чының төсе бертуктамаенча үзгәреп, минут саен кырыгар төскә кереп торалар иде. Болар бер караганда чем-кара кебек күренә, бер караганда соры кебек, бер караганда яшел кебек, бер караганда кызыллы-каралы чуар кебек, бер караганда һәртөрле төснең калдыкларыннан ясалган корама кебек күренәләр иде.

«Тәрҗеман»ның креслосын бер күрү берлә генә нинди икәнлеген белерлек түгел, бер зур бүлмәгә әверелгән иде. Аның идәннәрендә бик күп гәзитәләр, өстәлендә бик күп бакыр акча, диварларында аурупача, гади татарча, төрекчә, иранлыча, голямаларча киемнәр эленгән кебек, өстәл янындагы каләм-кара савыт янында бик зур күперелеп тора торган әллә нинди капчыклар да күренә иде. Теге сәрабның хәрәкәте берлә моның да бөтен бүлмәсе, бөтен әйберләре төрле төскә керсә дә, ул үзе уңга караганда тәмам кара йөзле кебек күренсә дә, сулга борылганда аның берлә җир, күк, сыек кына ал төстә, сулга таба борыла иде.

Сул яктагы бүлмәләр тагы башкача иде, «Таң»чы бүлмәсендә әллә нинди сукалар, тырмалар, көрәкләр, сәнәкләр, өем-өем ашлыклар күренә, бер читтә тимерче өргечләре, чүкечләре, ыргаклары, әллә нинди фабрикларның машиналары күренә. Шулар арасында өстәл өстендә каләм берлә кәгазьләр күзгә ташлана иде. «Ислях»чының бүлмәсе әллә нинди, шәкерт дисәң, шәкерт түгел, студент дисәң, студент түгел, әллә ничек ике арада калган кешенең бүлмәсе кебек күренә иде. Аның өстәл өстләрендә каләмнәр, кара савытлар арасында ак якалар ята. Алар берлә бергә иске китаплар, шиблет янында бер иске читекнең балтыры күренеп тора иде. Бу яктагы төс кызыл булса да, аның «Таң»чы өстендәге кызыллыгы берлә «Ислях»чы өстендәге кызыллыгы арасында аерма барлыгы күренеп тора иде.

Болар һәммәсе дә бер-берсенең бүлмәләрен карап бетереп, бер-берсеннән көләргә, үзләренең бүлмәләренең иң яхшы икәнлеген сөйләргә, шуның хакында кычкырышырга өлгерә алмадылар, тагы баягы кебек тавыш ишетелде. Өйрәнеп киткәнгә, бу юлы «Мәгыйшәт»че дә куркып-нитеп истибрасын туктатмады. Тагы бүлмә караңгыланды. Тагы әллә нинди яшен утлар үткән кебек булды. Тагы бераздан, болыт астыннан чыккан кояш кебек, бүлмә ялт итеп китте. Һәммәсенең күзенә сул яктагы «Ислях»чы берлә «Таң»чы арасында креслоның әллә нинди аллы-кызыллы роза берлә тутырылып бетерелгән гөлбакчасына әверелүе күренде. Боларның күзләре шул чәчәкләр берлә тулган бүлмәгә өйрәнеп җитәргә өлгермәде, ишектән җете ак кием кигән вә кара сачләре өстенә чуклы ак калфак кигән, бөтен күкрәкләрен ал чәчәкләр берлә бизәп бетергән бер матур кыз кереп, акыртын гына гөлле бүлмәгә таба бара башлады. Залның уртасына җиткәч, борынына кергән истән котылыр өчен, еш-еш кулындагы чәчәкне иснәп, бүлмәсенә барып керде. Әллә кайдан телеграм алынган кебек, боларның һәммәсе дә берьюлы моның Сылу туташ икәнен белделәр.

«Мәгыйшәт»че бераз карап торгач: «Сәтре гаурәт фарыз, хатыннарның йөзләре гаурәт», — дип кычкырды. Авызы эченнән генә: «Кара, сәдиүннәре, биле нинди», — дип, күзен йомып, үзен шуны кочаклаган иттереп, үбә иттереп хыял кыла башлады. «Вакыт»чы үзеннән генә: «Матурың матур икән дә, бай түгелдер шул, эш акчада, акчада»,—дип, акча хакында уйлый башлады.

«Йолдыз»чы кычкырып: «Безнең бу Сылу туташ берлә утырганны кеше күрмәс микән?» — диде. Авызыннан гына: «Чибәр бит! Чибәр!» — дип, үзенең өстләрен төзәтеп, үзенә илтифат иттерер өчен «эһем, эһем» дип куйды. «Тәрҗеман»чы эченнән генә: «Тол микән, түгел микән, тол булса, иреннән акча калды микән?» — дип уйлап, шуңарга якынлашыр өчен, «бөтен мөселман съезды» кебек, бер-бер съезд ясарга уйлый башлады. «Таң»чы берлә «Ислях»чы Сылу туташның үзләре берлә бергәлеген күреп, эчләреннән үзләренең тегеләрне җиңүләренә шатлана башладылар. «Таң»чы, «Вакыт»чының бик кызыгып караганын күргәч, кулы берле ишарә кылып,

«корсак»ны күрсәтте «Вакыт»чы бик каты: «Малайлар!» — дип кычкырды. «Йолдыз»чы, бераз кызарып, болар миннән дә көлмәсеннәр дип, беркемгә дә карамаенча гына: «Таң»ны бит ябылган диләр, имеш, аның редакторы да үлгән диләр, имеш»,— дип куйды. «Таң»чы, теш арасыннан кысып кына: «Шпиун, провокатор!» — диде «Йолдыз»чы үзен-үзе йолар өчен кебек: «Юк, мин кешедән генә ишеттем, алай булса, дөрест түгелдер» — диде дә башын аска иде. «Вакыт»: «Юк, юк, алар ислам җегетенә катышырга хаклары юк, мин җиде миллион әһле исламның вәкиле, мин ул малайларның катышуына риза түгел»,—диде.

«Мәгыйшәт»че: «Болар инде имансызлар, имансызлар»,—диде. «Вакыт»чы аның артыннан: «Имансызлар, имансызлар. Менә әле Австралия дигән җирдән бер эшченең хатын бер адвокат берлә качкан. Казанда да бер приказчик берсенең хатын берлә мунчага барган. Менә бөтен дөньяның эшчеләре ничек берләшәләр»,— дип кызуланып-кызуланып: «Америкада бер япун бер француз эшчесе берлә авызын-борынын канатып сугышканнар»,— диде дә, үзен тәмам җиңдем дип белеп, кычкырып көлә башлады. Сылу туташ бу мәгънәсез уйларны һәммәсен күңеленнән сизенеп торганга, бу сүзләрне ишеткәнгә эче пошып, чәчкәләрен еш-еш исни башлады.

Менә тагы бик зур тавыш ишетелде. Тагы күз аллары караңгыланды, тагы яшен уты кебек утлар йөри башлады. Тагы кояш чыккан кебек зал ялтырап, яктырып китте. Боларның күз алларында бөтен татар галәменең манзарәсе ачылды. Әнә бөтен йорт-җирләре салам берлә ябылган татар авылының яшел тимер башлы (түбәле) өйләре йөзек кашындагы фирәзә кебек кенә кечкенә булып, саламга баткан кебек күренеп тора. Әнә авыл кызлары төрле-төрле ачык төстәге сары, кызыл яшел күлмәкләрдән киндер сугалар. Әнә татар егетләре, башларыннан кәләпүшләрен ташлап, алты берлә ашлык сугалар. Әнә татар карты, үзеннән аз гына яшь, йә үзеннән дә карт арбага кызыл ястык салып утырып, ишанга бара. Әнә татар мулласы кайнап тора торган зур самавыр янында изү бавын тишеп, кәләпүшен салып, чәй эчеп утыра. Әнә татар бае дөньядагы һәрбер төрле товарны тутырган кибетне ачып,

кесәсендәге өч сум акчасына һаваланып, кибет алдындагы урындыкка утырып тора. Әнә әүем-әүем ташландык казарма кебек өйләр арасында карага, корымга буялып беткән бер шәкерт самавыр куеп маташа, аның яныннан берсе кибеттән бер тиенлек күмәч алып кайтып килә. Әнә хахулларның буяган өйләре уртасында калган башкорт, бабасының зиярәте өстенә утырып, тирә-янындагы кешеләрне күрмәенчә, бабаларыннан калган көйләргә курай тарта. Әнә атка атланып, кыргыз егете, көтелмәгән кадерле кунактан куркып, Кытайга таба атын кыйнап-кыйнап чаба. Әнә шуларның уртасыннан Идел ага: кечкенә-кечкенә парахутлар күренә. Әнә бер көтү ак яка кигән яшьләр бик күп бер җиргә өелгән мәсҗедләр арасында нишләргә белми аптырап йөриләр. Әнә кечкенә генә китап кибете, янындагы май, чәй, шикәр, читек-кәвеш товарлары арасында үзенең кечкенәлегеннән оялган кебек, уртада яшеренеп кенә тора. Әнә тагы, заводларга, фабрикаларга каплар ташучы эшче татарлар, озын эштән арып кайтканның соңында, былчырак киемнәрдән, былчырак савытлардан ашап яталар. Әнә аның артында тагы киләчәк татар галәме. Бу манзарәләр боларның шулкадәр дикъкатьләрен җәлеп итте, болар шундагы нәрсәләрне карый-карый үзләрен онытып җибәреп, үзләренең күңелләреннән шулар хакында уйларга чумып, шуларның кай якка таба хәрәкәт итүе хакында фаразлар диңгезендә йөзә башладылар. Менә боларның күз алдына Аурупага киткән бер кечкенә генә кыз бала, бер гимназист килеп чыктылар. «Таң»чы берлә «Ислях»чы, балалар кебек шатланып: «Уку китте. Уку!» — дип кычкырыша башладылар. «Мәгыйшәт»че, теге балаларның кулга-кул тотышканын күргәч, бик ачы тавыш берлә: «Хәрәм!» — дип кычкырды. Бөтен зал дерелдәп китте. «Тәрҗеман»чы тавышны ишетү берлә әле уңга, әле сулга әйләнә башлады.

Ул да булмады, савырлы читек кигән, озын казаки кигән, елтыратып алдырган башына зәңгәр кәләпүш кигән, мыекларын сукыр тычкан юлы кебек иттереп кенә калдырган бер кеше берлә капчык төсле күлмәк кигән, алдына-артына әллә никадәр тәңкәләр таккан, кулына әллә нинди беләзекләр, төймәләр кигән, майлап тараган сачләрен яшерер өчен кызыл француз яулык

бәйләгән, аягына каймалы читек кигән абыстай килеп чыкты. Болар татар дөньясының берсе бер ягыннан, берсе бер ягыннан чыгып, берсенә берсе каршы килеп, абыстай, йөзен яшереп кенә, кулын теге иргә сузды. «Йолдыз»чы «Мәгыйшәт»ченең «хәрәм» диергә хәзерләнгәнен сизеп алып, анын сөаль Мөкаддәренә җавап өчен: «Аларның иҗабе кабуллары булуы ихтималы бар»,— диде. «Вакыт»чы: «Әйе, әйе», — дип, аның сүзен беркеттерде. «Мәгыйшәт»че, аларның сүзенә риза булган кебек, бер сүз дә дәшмәде. Шул ара да булмады, һатифтан килгән тавыш: «Бөтен теләгәннәреңезне кабул итәм. Менә шул татарлар хакында ни теләсәңез, сезнеңчә булсын»,— диде. Болар һәммәсе дә: «Элгәре мин. Элгәре мин»,— дип кычкырыша башладылар. Моныңча сүзгә катышмаган Сылу туташ үзенең чәчәкләре арасыннан чәчәкләрдән матур тавышы берлә: «Татар галәмендә матурлыкны аңлар өчен, аның матурлыгын күрер өчен юл ачкан кеше, матурлык берлә ямьсезлекне аерыр өчен шәм яндырган кеше — «Тәрҗеман»чыдыр, элек ул сөйләсен»,—диде. Тегеләр берсе дә бу кадәр матур кызның бу кадәр матур тавышына каршы килергә көчләре булмаганга, башларын иделәр. «Тәрҗеман»чы аягүрә торып: «Бөрадәрләр!» — дип сүз башлады. Үзенең мәктәпләргә хезмәт итүен, үзенең ысулы җәдидә өчен тартышуын сөйләде.

Һатиф: «Аларын без синнән күп беләмез. Син менә шул татар галәменең киләчәген ничек булуын телисең, ниләрнең бетүен телисең?» — диде. «Тәрҗеман»чы тагы бер уңга, бер сулга борылып: «Бән бу яшь бәрадәрләрем берлә бергә», — дип, тагы үзенең хезмәтләрен сөйләргә тотынды.

Һатифтан: «Ишеттек, ишеттек, үткәнне сөйләмә, киләчәкне сөйлә»,— дигән тавыш ишетелде. «Тәрҗеман»чы тагы: «Бән диюрем...» — дип башлап, тагы үзенең үткәнен сөйләргә тотынды. Һатифтан бик ачулы тавыш ишетелде. «Тәрҗеман»чы, башына бик зур таш төшкән кебек, шып итеп утырды. Һатиф: «Сүзе аңлашылмады, ни теләгәне мәгълүм булмады, шуның өчен татарны искечә калдырам»,— диде.

Аның артыннан булмады, «Йолдыз»чы торып: «Ул менә шуны әйткән булырга тиеш: әле бит ысулы җәдидәне яратмаучылар бар, имеш, ысулы җәдидә дингә мохалиф, диләр, имеш»,— дип, «Тәрҗеман»ны якламакчы булды. Һатифтан: «Татарга тылмач кирәкми», — дигән тавыш ишетелгәч, куркуыннан «Йолдыз»чы көчәнеп көлеп: «Юк, мин үз хакымда әйтәм, мине исламны яратмый диючеләр бар, имеш. Ул ифтира, минем «Мөгаллимел әүвәл»ем бидгать диләр, имеш. Китапларда «ля» хакында хәдис бар, имеш»,— дип сөйли башлады. Һатифтан: «Син имеш-мимешеңне калдырып тор. Син хәзер гәзитәгә мәкалә язмыйсын. Менә шул татарны нишләмәкче буласың? Нинди үзгәрү телисең?» — диде. «Йолдыз»чы: «Әйе, мин шуны әйтәм шул, ул ысулы җәдидәгә каршы килүчеләр һәр халыкта да булган, имеш. Мине яшьләр яратмый, имеш, минем эчем дә бик сул, ләкин әле бит мөдаба бар», — диде. Һатифтан ачуланган тавыш ишетелде «Йолдыз»чы да шуның артыннан ук, сүзен бетермәенчә, куркуыннан урындыкка утырды, һатиф: «Моның да сүзе аңлашылмады, шуның өчен татар үзгәртелмәенчә калды. Моннан соңгыларыңыз ачык сөйләңез»,— диде. «Вакыт»чы торып: «Менә бөтен эшне бозучылар — яшьләр. Мәдрәсәдә забастовка ясаучылар — яшьләр, мәдрәсәләрдән риза булмаучылар — яшьләр, безнең кебек олугларны сүгүчеләр — яшьләр, эшчеләрне котыртучылар—яшьләр, гәзитәләр чыгарып, безнең гәзитәләрнең базарын төшерүчеләр — яшьләр, шуның өчен мин синнән шул яшьләрне бетерүне телим»,—диде. Һатифтан: «Кабул иттем»,— дигән тавыш ишетелде. Татар галәмендәге теге ак якалы кешеләрнең бердән еглаулары тавышы ишетелде. Боларның алдындагы абзый берлә абыстайның битләре җыерчыкланып китте, аркалары бөкерәйде, куллары калтырый башлады. Аның артыннан «Мәгыйшәт»че торды: «Замана бозылды, әллә нинди китаплар чыга башлады. Гәзитә чыкты, театр булды, хатыннар, ирләр бергәләшеп бии башладылар. Шәригатькә илтифат бетте, тәһарәтсез йөрүләр күбәя башлады. Безнең усал голяманың кадере бетте. Коръәндә әйткән «Сәләфләр юлыннан чыгу хәрәм дигән»,—диде. һатифтан: «Юк, әйтмәгән», — дигән тавыш ишетелде.

«Мәгыйшәт»че сугышырга хәзерләнгән әтәч кыяфәтен алып: «Ля нөсәллим әйткән! Булыр, булыр», — дип кычкырды. Һатифтан: «Йомышыңны сөйлә, моназарә кылырга бу Кышкар мәдрәсәсе түгел»,—дигән ачулы сүз ишетелде. «Мәгыйшәт»че: «Шуларның барысының сәбәбе — ысулы җәдидә берлә яңа китаплар, шуларны бетер!» — диде. Һатифтан: «Кабул иттем»,—дигән тавыш килде, татар дөньясындагы ысулы җәдидә мәктәпләренең җимерелү тавышы ишетелде.

Китап кибете куй мае астында калды, абзый берлә абыстайның кесәсеннән кечкенә генә кара такта, кара каләм, бер китап төшеп тузан булып күккә очты. Моңарга бик ачуы килеп, «Исләх»чы, сикереп торып: «Безнең халыкның артка калуына сәбәп шул надан мәдрәсәләр, шул сасы мәдрәсәләре, шуларда укыла торган сафсаталары. Шулар безне харап иттеләр, шулар безне Аурупаның аяк астында изделәр, шулар безне наданлыкка чумдырдылар, бетер шуларны!» — диде. Һатифтан: «Кабул иттем», — дигән тавыш ишетелде. Татар дөньясында дөбер-шатыр килеп мәдрәсәләр җимерелде. Аларның өстләреннән чыккан тузан, кер-күмер вагы күккә күтәрелде, абзый берлә абыстайның кесәләреннән такта тышлы яшел кәгазьгә язылган китап төшеп көлгә өйләнеп, тузаны күккә очты.

«Таң»чы торып: «Бөтен халкымызның артта калуының иң зур сәбәбе — әрәм тамаклар: муллалар, зур корсаклы байлар, аларның тәрилкәләрен ялаучы мөхәррирләр, эшче вә авыл халкының ач булуының сәбәбе — кап-йот алпавытлар, аларның теләүләрен дин дип күрсәтүче муллалар, фабрикантлар. Шуның өчен шул әрәм тамак муллаларны, зур корсаклы байларны, кап-йот алпавытларны, тәрилкәче мөхәррирләрне, эшче халыкны алдарга корал ясалган динне бетер!» — диде. Һатифтан: «Кабул иттем!» — дигән бер тавыш ишетелде. Татар галәмендә кибетләр җимерелә башлады. Чәй эчә торган мулла самавыры янында егылды, мәсҗедләрнең манаралары җимерелде. Берничә редакциянең вывескалары дөбердәп төште, абзый берлә абыстай кесәләреннән биш-алты бакыр акча шылтырап төшеп, көлгә әйләнеп, күккә очты. Сылу туташ, торып, матур тавышы берлә: «Мин матурмын, мин матурлыкны яратам,

минем тавышымны музыка, диләр, минем сүземне әдәбият, диләр, минем ясаган нәрсәмне художество, диләр. Мин татар галәменә матурлык кертер өчен килдем. Ләкин мин шул ямьсез иттереп кырган мыеклы абзыйның ямьсезлегенә, аның башыннан килә торган куй мае исенә чыдый алмыйм, мин ул абыстайның капчык кебек теккән күлмәкләрен, зур калфакларын күрә алмыйм. Аның матур сачен тарап ямьсезләтүенә риза була алмыйм, шуның өчен шул ямьсезлекләрне бетер!» — диде. Һатифтан: «Кабул иттем!» — диде. Татар галәмендә теге ишанга баручы карт егылды. Әллә нинди киң күлмәкләр көлгә әверелделәр. Әллә нинди сакал-мыек йоннары күккә очтылар. Сасы исләр бетеп киттеләр. Абзый берлә абыстайның да төсләре үзгәрде. Аларның тәннәрендә хәрәкәт бетте. Алар зур таш кебек катып калдылар. Һатифтан: «Тагы ни теләвеңез бар?» — дигән тавыш ишетелде. Һәммәсе дә, үзләренең догалары кабуллыгына шатлану берлә, тавышка илтифат итмәенчә, бер җавап та бирмәделәр. Һатифтан: «Күк капусы ябылсын!» — дигән тавыш ишетелде. Күз алды караңгыланды, утлар йөри башлады. Тагы яшен ялтырады, тагы зал яктылык берлә тулды, тегеләре теге татар галәменең юклыгын, үзләренең урыннары үзгәргәнен күреп, басып тора торган абзый берлә абыстайга таба барып: «Мин җиңдем, хода минем теләгәнемне кабул итте. Абзый берлә абыстай минем берлә булалар», — дип кычкырыша башладылар. Һәммәсе дә тизрәк тегеләрне алыр өчен, йөгерешеп барып, аларны тотмакчы булдылар. Кулларын сузарга өлгерә алмадылар, боларның җилләре берлә абзый да, абыстай да ватылып китеп, көлгә әйләнделәр. Моны күреп, тегеләре һәммәсе котлары очып урыннарына китеп утырдылар. «Мәгыйшәт»че генә залда калып, кесәсеннән ачкычларын чыгарып, шәкертләрнең компанияләрендәге тавышларны чыгарып: «Мин җиңдем, мин җиңдем»,—дип, биергә тотынды. Бөтен бүлмә караңгылык берлә тулды.

Татар мәсьәләсе хәл кылынды.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Тәйе зәмин кылу* — җир шарын йөртеп чыгу.

*Истибра* — тәһарәт кылу.

*Истинҗа* — тәһарәттән соң пакъләнү.

*Мәсләк* — токан юл,принцип.

*Исмасам* — ичмасам.

*Нәҗасәт* — пычраклык.

*Гализа* — тупас, әдәпсез.

*Бурада* — биредә.

*Сәраб* — рәшә.

*Шиблет* — штиблет.

*Сәтре гаурәт* — йөзне каплау.

*Сәдиүннәре* — күкрәкләре.

*Әһле ислам* — мөселманнар.

*Тишеп* — чишеп.

*Әүем- әүем* — өем- өем.

*Сөаль мөкаддәренә* — алдан билгеле булган сораулар.

*Мөхалиф* — каршы килә торган.

*Ифтира* — яла ягу.

*Ля* — юк.

*Мөдара* — саклык, саклану.

*Сәләфләр* — борынгылар.

*Ля нөсәллим* — риза түгел.

*Моназарә* — бәхәс.

*Коруне вөста* — урта гасырлар.

**Күк капусы** — Хикәя Г.Исхакыйның Казанда «Үрнәк» матбагасында 1909 елда чыккан «Җыентык» исемле китабында басылган. Нашире: Хөсәен Әбүзәров.

«Идел» гәзитәсенең 1909 ел, 19 декабрь санында «Яңа әсәрләр» дигән рубрикада болай язалар: «Мәшһүр мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхакый

тарафыннан язылмыш бу әсәрдә иң башта Русиядәге мөселман гәзитәләренең бәгъзеләрен тәнкыйть вә анларның фикер вә мәсләктә ихтиляфларының нәтиҗәсе уларак, татар галәменең һәр эше искечә калуы, яңармага торганнарының йимерелүе тасвир ителмеш».

Хикәядә социаль тормышның аерым бер үсеш дәверендәге хәлләр тасвирлана. Гәзитә-журналларга да бәяләмәләр «таңчылар» күзлегеннән чыгып бирелә. Шулай да Г.Исхакый биредә «Таң йолдызы» битләрендә «Вакыт» гәзитәсе белән бәхәскә кереп язган хикәя («Корсак») һәм мәкаләләрендәге артык кискенлекне үзе дә андый кебек, һәрхәлдә, әсәрнең нигезенә «татарда бердәмлек булмау, традицияләрдән, элекке тәҗрибәләрдән ваз кичү милләт үсешен тоткарлый» дигән фикер салынган.

*Күк капусы* — дини ривайәттә: күкнең капкасы бар, елга бер тапкыр изге Кадер кичәсендә генә ачыла, изге күңелле кешегә генә күренә, күргән кеше бәхетле була, шулчагында ул ни теләсә, шул кабул була.

*Һатиф* — күктән иңдерелгән тавыш.

*«Вакыт»* — иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис, тарихи-мәдәни гәзитә *(21 февр. 1906 — 26 гыйнв. 1918, Оренбург).*

*«Йолдыз»* — иҗтимагый-сәяси һәм әдәби гәзитә *(15 гыйнв. 1906 —21 июнь 1918, Казан).*

*«Таң» («Таң йолдызы»)* — Г.Исхакый оештырган беренче рәсми сәяси, әдәби һәм фәнни гәзитә *(18 май — 17 нояб. 1906, Казан).*

*«Ислях» («Әлислях»)* — гыйльми, әдәби гәзитә *(3 окт. 1907— 22 июль 1909, Казан).*

*«Дөнья вә мәгыйшәт»* — Оренбургта 1906 елның 31 декабрь (1) санынннан алып 1907 елның 8 апрель (13) санына кадәр «Дөнья вә мәгыйшәт», 1907 елның 15 апрель (14) санынннан 1918 елның декабренә кадәр «Дин вә мәгыйшәт» исеме белән чыккан дини-иҗтимагый журнал.

*«Сөлләм» («Сөлләмел-голүм»)* — китап исеме. Мантыйкның «Исагужи»дан соң икенче бүлеге (сөлләм-баскыч дигән сүз).

*Истибра кесәсе* — тәһарәт чүпрәген сала торган кесә.

*«Тәрҗеман»* — Россия җирлегендәге төрки халыклар арасында нәшер ителгән беренче милли гәзитәләрдән. 1905 елга кадәр гомум төрки һәм рус телләрендә, аннан соң гомумтөрки телендә чыга (*апр., 1883 —1918, Бакчасарай шәһәре, Кырым*). Мөхәррире Исмәгыйль Гаспринский.

*Мисвәк* — теш чистарту өчен үзенә бер төр агачтан ясалган таякчык; теш щеткасы.

*Савырлы читек* — ат сыртының арткы өлеше, янбаш тиресеннән эшләнгән күн куеп тегелгән читек.

*Француз яулык* — дүртпочмаклы зур чуар яулык.

*Иҗабе кабул* — өйләнешүчеләрнең алу-барулары турында ризалыкларын белдерүләре.

*«Мөгаллимел әувәл»* — Һади Максудиның (1868—1941) әлифба китабы. Г.Тукай да «Фикер» гәзитәсенең 1906 ел, 15 октябрь санында басылган «Яңа гәзитә вә журналлар һәм мәкаләләр» исемле мәкаләсендә бу китап хакында ирониялe сүзләр әйтеп үтә.

*Кышкар* — Татарстанның хәзерге Арча районы Кышкар авылы мәдрәсәсе XVIII гасыр урталарыннан алып 1918 елга кадәр яшәп килә. Телләр, дини гыйлемнәр укыту белән бергә мәдрәсәдә формаль логика — мантыйк укытуга зур игътибар бирелә. Мәдрәсә бәхәсләшү, моназарәләр уздыру белән данлыклы була. Кышкар мәдрәсәсендә Тукайның әтисе Мөхәммәдгариф, бабасы Зиннәтулла Әмиров, Уральскидан Камил Могыйгый белән күренекле артистка Галия Кайбицкаяның әтиләре Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин, татар әдәбияты тарихында билгеле урын алган Таип Яхин, драматург Фатыйх Халидиләр укыганнар.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б. 5-15.